СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО - ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | №133 (7306) | 7 ноябрь, 1991 ел. ПӘНҖЕШӘМБЕ | Бәясе 4 тиен.

## СССР Дәүләт Советы утырышы

МӘСКӘҮ (ТАСС). 4 ноябрьдә Кремльдә СССР Президенты М. С. Горбачев рәислегендә СССР Дәүләт Советы утырышы булды. Агымдагы моментка бәя биреп, ә ул мәсьәлә көн тәртибендә беренче булып тора иде, Президент «Без бик авыр критик ситуациядә торабыз» дип белдерде. М.С. Горбачев Россия Президенты тарафыннан тәкъдим ителгән радикаль экономик реформалар программасын хуплап чыгыш ясады.

«Россиялеләр тарафыннан әзерләнгән документлар бердәм килешеп эшләү өчен база була алалар», —дип ассызыклады ул.

Дәүләт Советы утырышының көн тәртибендәге мөһим мәсьәләләрнең берсе итеп экономик бердәмлек турында Договорга килешүләр пакеты әзерләү турында мәсьәлә иде. Барлык мөстәкыйль дәүләтләр вәкилләре әлеге Договорга кагылышлы килешүләр проектларын, аларны ратификацияләүгә тизрәк керешү өчен, эшләүне төгәлләргә теләк белдерделәр. Украина премьеры В. Фокин да шуны ук эшләде. Ул Украинаның якын көннәрдә Договорга кул куячагына ышандырды.

Дәүләтара экономик комитет (МЭК) структурасы һәм штатлары турында доклад белән дәүләт башлыклары утырышында МЭК рәисе постына тәкъдим ителгән И. Силаев чыгыш ясады.

Ул МЭКны экономик берлекнең югары органы —дәүләтләр башлыклары киңәшмәсе каршында отчет тотачак дип белдерде. МЭКка 5 блокка берләшкән 15 департамент керә. И. Силаев шулай ук 15 ноябрьдә әлегәчә яшәп килгән Союз Министрлыклары эшен туктатачак дип белдерде. Аларның кайберләре МЭК департаменты итеп үзгәртеләчәк. Дәүләт советы МЭК җитәкчесенең комитет структурасы һәм штатлары турындагы мәсьәләне ахыргача хәл итүне киләсе утырышка калдырырга дигән белдерүен исәпкә алды.

## 10 ноябрь—Совет милициясе көне




### Һәрвакыт сафта

Таныш булыгыз: район эчке эшләр бүлегенең уголовный җинаятьләрне ачу бүлеге өлкән оперуполномоченные, милиция капитаны Валерий Леонидович Гаврилов. 7 еллап бу бүлектә эшләү дәверендә Валерий Леонидовичка күпләгән җинаятьләрне ачуда катнашырга туры килде. Тирән белем, фикерләү сәләте, хезмәтенә игътибарлы һәм җаваплы караш аңа бу эшне заман кушкан дәрәҗәдә алып барырга ярдәм итә. Читтән торып Казан Дәүләт университетында уку шулай ук аның мәгълүматын киңәйтә, теоретик белемен баета.

## СЕМИНАР ХУҖАЛЫКТА ҮТТЕ

31 октябрьдә колхоз-совхозларның профсоюз комитетлары рәисләре семинары булып үтте. Ул «Россия» колхозы профсоюз оешмасы базасында узды.

Авыллардан җыелган кунаклар алдында хуҗалык рәисе Ю. В. Терентьев чыгыш ясады. Ул профсоюз әгъзаларының игенчелектә һәм терлекчелектә фидакарь хезмәтен хуҗалык ирешкән уңышлар белән бәйләде. Бер үк вакытта авыл эшчәннәрен социаль яклау чараларын, йортларга газ кертү, урамнарны, ферма тирәләрен асфальтлау, торак салу проблемаларын яктыртты.

Аннан соң семинарда катнашучылар авыл мәдәният йортында булдылар. Биредә җылылык батареялары алмаштырылган, реконструкция эшләре бара.

Профком рәисләре техника паркындагы көнкүреш комплексы —кызыл почмак, сауна, ял бүлмәсе, аларның җиһазланышы белән таныштылар. Колхозның профком рәисе В. Н. Григорьев җирле комитетның эшен оештыру турында сөйләде. АПК работниклары профсоюзы райкомы секретаре Р. Н. Садыйков башлангыч оешмаларда отчет-сайлау җыелышлары үткәрү, урыннарда профсоюз активын укыту, хатын-кызларның, гаиләнең хәлен яхшырту, авылда аналарны һәм балаларны саклау буенча ТССР Министрлар Кабинетының махсус карарын үтәү, хезмәткә түләү мәсьәләләрен яктыртты. Профсоюз райкомының баш бухгалтеры В. П. Алексеева чыгышы профкомнарның финанс эшчәнлегенә кагылышлы булды.

Киңәшмәгә АПК работниклары профсоюз райкомы рәисе Г. К. Пакшин йомгак ясады.

Агропромышленность комплексына кергән шәһәр предприятиеләре һәм оешмалары профкомнары белән шундый ук эчтәлектәге семинар «Октябрьскагропроммехмонта ж» ПМКсы профсоюз оешмасы базасында үткәрелде.

Р. НӘҖИПОВ.

## „Сәламәтлек. Хисләр. Матурлык“

**Бу көннәрдә Норлат пионерлар йортында үткәрелгән күңелле кичә шундый исем астында барды.**

—Кичәне Пионерлар йорты каршында өлкән класс укучылары клубын оештыруга беренче адым диярга була. Килешегез, шәһәрдә әлеге буын балалар өчен, ял итү, рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен урыннар юк дәрәҗәсендә бит. Төрле кызыклы чаралар циклы үткәреп без бераз булса да бу мәсьәләне хәл итүгә өлешебезне кертергә уйладык. Бу цикл «Пионерлар йорты чибәре», «Модельләр күрсәтү», «Күңеллеләр һәм тапкырлар» конкурслары, «Могҗизалар кыры» һәм башка чараларны үз эченә алачак, ди. Пионерлар йорты директоры Гүзәл Әһлиуллина.

Кичәне Пионерлар йортының фантазиягә бай, инициативалы мәдәни оештыручысы Ольга Мөхәммәтҗанова оештырды. Кичә нигездә кызлар катнашында барды. Бәйләү һәм макраме түгәрәге җитәкчесе А. Ф. Цветкова белән берлектә алар үзләренең хезмәт җимешләрен күрсәттеләр, икенче мәктәпнең «Грация» группасы, В.А Пирогова һәм шулай ук үзләре теккән киемнәрне демонстрацияләделәр. Кичәнең бу өлешен «Модалар театры» дип атасаң да артык булмас иде. Пионерлар йорты рәссамы Е. В. Илялова ярдәмендә Эльвира Батыршина, Таня Маркелова, Наташа Краснова зур осталык белән театр артистлары ролен башкардылар. «Итагатьлелек дәресләре», анкета буенча үз-үзеңне табу кагыйдәләре, макияж, матур киенү серләре белән таныштыру үткәрелде. Хәтта хисләр темасына кайбер кызыклы номерлар да күрсәтелде. Әйтик, ничек егетләр белән танышырга һәм башкалар. Соңыннан алып баручы Женя Семакова кичә буена барган төрле конкурсларның йомгакларын белдерде. «Иң сагышлы», «Иң шат күңелле», «Иң чибәр» һәм «Иң оста куллы» кызлар кызыклы грамоталар белән бүләкләнделәр. Өстәвенә кичәдә катнашучыларның һәркайсы кулларына калла чәчәкләре тоткан килеш таралыштылар.

Ф. ВӘГЫЙЗОВА.

## Уңыш бәйрәме

«ҮРНӘК» КОЛХОЗЫ. Хуҗалык узган шимбәдә «Уңыш бәйрәме» үткәрде. Ул игенчеләр өчен генә түгел, терлекчеләр өчен дә бәйрәм булды. Анда колхоз рәисе Н.Ш. Шәрапов колхозның узган урып-җыю чорындагы эшчәнлегенә кыскача анализ ясады. Хуҗалык игенчеләре катлаулы елда гектардан 20,5 центнер уңыш алдылар, терлек азыгы әзерләү, чөгендер үстерүдә дә елына күрә әйбәт кенә күрсәткечләргә ирештеләр. Колхоз рәисе урып-җыюда фидакарь хезмәт куйган Тәлгать Харисович Галимов, Миннебай Рәхимҗанович Идиатуллин, Шәрифҗан Хәйдәрович Хәйдәрҗанов һәм башка алдынгыларны мактап телгә алды, шунда ук киләсе елга ирешәсе үрләрне, киләчәк планнарны да бәян итте. Аннан колхозчылар бәйрәмне аш, чәй табыны артында дәвам иттеләр. Сый-нигъмәтле өстәл артында күңелле сөйләшү, уен-көлке шактый озакка сузылды.

И. ШӘЙХИЕВ.

## Көенечле йомгаклар

МӘСКӘҮ (ТАСС). Оператив мәгълүматларга караганда, октябрь азагына ярты миллион гектарда ашлык җыелмыйча калган. Аның күп өлеше Иркутск һәм Чита өлкәләре, Бурятия һәм Тува кырларында кар астында калды. Бу ашлыкны юкка чыккан дип исәпләргә.

Тулаем ил буенча урып-җыю вакытында 157 миллион тонна ашлык суктырып алынган. Бу 1990 елдагыдан 62 миллион тоннага ким. Дәүләт ресурсларына, ссуданы кире кайтару исәбенә 39,1 миллион тонна ашлык керде. Ул дәүләт заказыннан 51 процент, яки суктырылганга карата 24 процент тәшкил итә. Чагыштырма: узган ел дәүләт барлык төр хуҗалыклардан 65,8 миллион тонна ашлык сатып алды. Дәүләт заказын РСФСРның тик 15 өлкә һәм республикасы, Украинаның 6, Белоруссиянең 4 өлкәсе генә үтәде.

Шикәр чөгендере һәм яшелчә уңышын җыю төгәлләнеп килә. Татлы тамыр 51 миллион тонна, узган елгыдан 14,5 миллион тоннага кимрәк хәзерләнде. 10,2 миллион тонна яшелчә сатып алынды. Бу узган елгы белән чагыштырганда 78 процент дигән сүз.

## Ике як та отты

Быел колхозның чөгендер басуына чыккан апайлар арасында бик өлкән яшьтәгеләрне дә күрергә була иде. Аңа бер дә аптыраучы булмады, чөнки Роза апа Вәлиәхмәтова, Роза апа Сәлахова, Мөнирә апа Абдрахманованың тынгысызлыгы, эшсөярлеге күпләргә мәгълүм инде. Пенсиягә чыкканчы да алар колхозның төрле эшенә йөрделәр, чөгендер иктеләр. Инде менә лаеклы ялга киткәч тә кул кушырып утырасылары килмәде. Роза апа Вәлиәхмәтова 7,15 гектар чөгендер эшкәртергә булды, калган апайлар да 2 гектар, 5 гектар участок алырга ризалаштылар һәм аны яшьләрдән калышмыйча башкарып та чыктылар.

Тынгысызлар яшьләр арасында да табылды. Декрет ялында утыручы Гөлсинә Сафина белән Рәмзия Әхсәнова шулай ук икесенә бергә 3 гектар җир алып эшләделәр. Бу категория хатын-кызларга хезмәт хакы 20 процентка артыграк түләнде. Аның каравы, колхоз эшче кулларга кытлык кичермәде. Әнә шулай һәр ике як өчен дә отышлы булды бу ярдәм.

В. КАНӘФИНА,
экономист.
«Игенче» колхозы.

**Профсоюзларда отчет-сайлаулар**

# Эшлекле сөйләшү

Ике ел артык гомер мөстәкыйль хуҗалык өчен күп вакыт түгел. Озак еллар читтәге бригада булып яшәгән «Таң» колхозы мөстәкыйль хуҗалык булып аерылып чыккач, шул вакыт эчендә дә иркен сулыш алды. Бу хуҗалыкта булып үткән профсоюз оешмасының отчеты барышында да ачык чагылды.

Отчет белән чыккан профсоюз комитеты рәисе Вәзир Әхмәтвәлиев колхозчыларның быелгы хезмәтләренә һәрьяклап анализ ясады. Игенчелектә эшләүче профсоюз әгъзалары тырышлыгы мактауга лаек, уңыш уртача район күрсәткеченнән күпкә югары. Хәер, терлекчеләр дә үз участокларында сынатмыйлар. Профком рәисе боларны конкрет саннар, дәлилләр белән ныгытты.

Җыелышта уңыштан бигрәк алда торган бурычлар турында сүз күбрәк барды. Әсхәт Миннеголов, мәсәлән, техникадан нәтиҗәле файдалану, аны саклап тоту мәсьәләләрен яктыртты.

Колхозда төзелеш алып барыла торган объектлар байтак. Бүгенге көндә берничә торак йорт салына, клуб кору эше башланган. Быел бикколлылар мәчет өлгертеп җиткергәннәр, моңа да хуҗалыкның өлеше кергән. Колхоз рәисе Вәзир Сәгыйров, башка күп кичектергесез проблемалар белән бергә, төзелештә эшне тизләтү чараларына да тукталды. Вәзир Сәлимовичның моңа басым ясавы һич очраклы дип булмый, чөнки алда тагын корасы объектлар да байтак. Яшьләрне авылда калдыру өчен тагын торак кирәк. Механизаторлар җыелышта яңа мастерской мәсьәләсен кузгаттылар. Саный китсәң зарури объектлар тагын да бар.


Профсоюз әгъзалары бу сөйләшү барышында терлекчелекне үстерү, тармакның нәтиҗәлелеген күтәрү, работниклар өчен һәр хезмәт урынында нормаль шартлар булдыру, социаль мәсьәләләр хакында да эшлекле сүз алып бардылар.

**Г. ӘХМӘТШИНА.**

---

Тәлгать Фаязович Һилалов (рәсемдә уңда) «Норлатнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсендә 1984 нче елдан бирле эшли. Байтак вакыт ДНС начальнигы булды, быелдан нефтьне комплекслы кудыру һәм хәзерләү цехы начальнигы вазифасын башкара. «Иң яхшы остаз» исемен яулаган, күп мактау грамоталарына, XII нче бишьеллык ударнигы исеменә лаек булган Тәлгать Фаязович яхшы белгеч булуы өстенә үрнәк гаилә башлыгы да.

Рәсемдә сез аны 4 нче ДНС операторлары бригадиры Г. Г. Стекольщиков белән бергә күрәсез.



Н. Квашнина фотосы.

---



ТАНЫШ БУЛЫГЫЗ: «Знамя Октября» колхозы сыер савучысы Гөлсирә Зөфәровна Рәхмәтуллина.

Ачык йөзле, күркәм холыклы Гөлсирә Зөфәровна 16 еллап колхозда чөгендер икте, төрле эшләрдә йөрде. Уңган һәм тырыш, карусыз булганы өчен иптәшләре дә, колхоз җитәкчеләре дә үз иттеләр аны. Инде соңгы 9 елын Октябрино фермасында сыерлар сава. Малларны яратып, үз эшен җиренә җиткереп башкара ул, терлекче хезмәтенең авырлыкларыннан зарланырга бер дә яратмый. Хәер, Рәхмәтуллиннар гаиләсе гомумән эшчән, тырыш халык. Гөлсирә апаның ире Мөбәрәкша Гаделшинович та күптәнге терлекче. Хәзер ул бозаулату бүлегендә эшли.

Ирле-хатынлы Рәхмәтуллиннар иртә таңнан фермага бергәләп юнәләләр. Уллары Илшатка да ата-анасының тынгысызлыгы, эшсөярлеге күчкән. Дөрес, һөнәрнең икенчерәген — механизатор хезмәтен сайлады ул, әмма Рәхмәтуллиннарның гаилә маркасы булган тырышлык, эшчәнлек биредә дә бик кирәк, бик урынлы.

Гөлсирә Зөфәровна әнә шулар белән дә горурлана. Колхозда даими эштә эшләп, гаилә мәшәкатьләрен дә тарту, татулыкка ирешү, уңган, тәртипле балалар үстерү — хатын-кыз хыялланган бәхет шул түгелмени инде?

---

**• Гади кешеләр турында**

# Мәхмүтовлар гаиләсендә

Гадәттә эшлеклелек, уңганлык хас гаиләдә балалар да шул сыйфатларны каннарына сеңдереп үсәләр, һәм шундый тәрбия алалар. Гомәр ага белән аның гомерлек тормыш юлдашы Гаршия апа да нәкъ шул сыйфатларга ия булдылар. Шулай булмый ни? Гомәр аганың ата-анасы Галимҗан һәм Ганҗамал апаны да бит Яңа Әмзә авылында мактап кына телгә алалар. Алар икәүләшеп колхозлашу чорының бөтен авырлыгын күрәләр, кая кушсалар шунда эшләп көн күрәләр. Дүрт баланың олырак дигәннәре акрынлап кул арасына керә башлады дигәндә генә Галимҗан ага кинәт кенә дөнья куя. Билгеле ки, балаларны укытып, аякка бастыру, аларның өстен-башын бөтен итеп тоту Ганҗамал апаның җилкәсенә төшә. Бөтен кыенлыкларга түзә ул, сынатмый. Олы улы Гомәр әтисе үлгәндә 15 яшьтә калып, йорт хуҗасы алып барган эшләрне башкара. Совет Армиясенә хезмәткә киткәч, әнисенә җылы гына хатлар язып тора». «Әни, саулыгыңны югалтма, үзеңне сакла!» — дип һәм хәтта энеләренә дә үгет биреп, ерактан ук, хат аша аларга үзенең киңәшләрен юллап тора. Хезмәтен уңышлы гына төгәлләп кайтуга, Ганҗамал апа улы авылда калу хәбәрен ишеткәч, сөенеп туя алмый. Ә Гомәр шунда ук шоферлыкка укып, озак еллар шул эшенә тугрылыклы булып кала. Сыер савучы Гаршия белән тормыш корып җибәрә. Ганҗамал апа тәмле ашлар пешереп өйгә җылылык, сафлык кертеп, балаларын эштән каршы алып тора. Тора-бара гаилә дә ишәя, берсе артыннан берсе биш бала дөньяга килә. Гомәр ага әнисе кебек үк үз балаларына һәрчак эшлеклелек, уңганлык үрнәкләре күрсәтеп яши. Чынлап та балалар шәфкатьле, киң холыклы булып тәрбияләнәләр. Кызлары Рәхилә авылны якын итте, читкә китеп бәхет эзләп йөрмичә, авылда почтага эшкә керә. Уллары Алиф та Әфганстанда хезмәт итеп кайтканнан соң колхозда тракторчы булып эшләде. Егет авылда каласын сизде һәм төптән үк уйлады да, Чистай авыл хуҗалыгы техникумына укырга керде. Тату, эшчән гаиләдә һәркем үз урынын таба тора. Эштә дә, ялда да алар турында гел мактау сүзләре генә яңгырый.

**С. ФӘТХЕТДИНОВА.**
Яңа Әмзә авылы.

---

**■ Саулыкханә**

# Психотерапевт Фәрис Галләм



Психотерапевт Фәрис Галләм исеме җөмһүрият чикләреннән дә үтеп чыкты, илгә мәгълүм булды. Аның турында күп газеталар язды һәм язалар. Мин мәшһүр табиб белән очрашу бәхетенә ирештем. Алай гына да түгел, Казанда цирк бинасында 21—23 октябрьдә дәвалау сеансында катнаштым. Һәм, әйтергә кирәк, сихәт алдым, шифасын күрдем, үземне әйбәт хис итәм.

Фәрис Галләм Бөтендөнья психотерапевтлар җәмгыяте әгъзасы икән. Дәвалау ысулы биотоклар һәм гипноз ярдәмендә. Бу алым белән, мәгълүм булганча, Кашпировский да дәвалый. Якташыбыз сеансы да рәвеше буенча аныкына охшаш.

...2 мең тамашачы урнашкан цирк залы. Шифа өмет итеп килүчеләр төрле-төрле милләттән: татарлар, руслар, чувашлар, мордвалар, марилар, удмуртлар һәм башкалар. Алар җөмһүриятебезнең шәһәр, районнарыннан чит өлкә, республикалардан — Киевтан, Санкт-Петербургтан, Башкортстаннан килүчеләр дә күп.

Сеанс, гадәттә, 2 сәгать буена дәвам итә. Аның беренче яртысында төрле-төрле чирләрдән дәваланган, табиб ярдәмендә савыккан кешеләр нинди авырудан дәваланулары турында сөйлиләр. Өметсезлеккә бирелгән сырхаулар авырудан арынулары турында сөенә-сөенә хәбәр итәләр. Күбесенең сөенечтән күзләрендә яшь ялтырый. Арада аллергия, эпелепсия, бронхит, бронхиаль астма һәм башка күп төрле чирләрдән арынучылар бар. Һәммәсе табибка ихлас күңелдән рәхмәтен белдерә.

Менә залдагы яктырткычлар акрынлап сүнә бара. Сихри моңга ия төсле музыка яңгырый. Ул да түгел, табибның кодрәтле сүзләре залга тарала.

«Мин сезгә үземнең бөтен чирләрне дәвалый торган биотокларымны җибәрәм. Алар сезнең тәнегездә, каныгызда һәм эчке органнарыгызда булган авыруларны дәвалый...»

Мондый тылсымчы, шифалы сүзләр сәгать буена яңгырый. Залда утырган халык, нинди милләттән булуына карамастан, инанып һәм ышанып кабул итә тәэсирчән бу сүзләрне. Һәм ниләр генә эшләми: беришләре һавада кулларын әйләндерә, икенчеләре гәүдәләрен хәрәкәтләндерә, өченчеләре көлә, дүртенчеләре елый. Гипноз һәркемне битараф калдырмый, татар табибының аһәңле сүзе җанга үтеп керә.

Сеанс азагына якынлаша: «Мин җибәргән биоток дулкыннары сезнең чирләрегезне акрынлап-акрынлап юып төшерә, барыгыз сау-сәламәт кешеләр булырсыз. Амин!!!»

Мин аның савыктыру серенә дә төшендем. Биотоклар, докторның тәэсирчән сүзләре кеше күңелендә яшәүгә, сәламәтләнүгә ышаныч уята, бу исә, үз чиратында, организмда теге яки бу чиргә каршы иммунитет барлыкка китерә — кеше сәламәтләнә. Шундый файда алучылар йөзләрчә, меңнәрчә. Аларның күбесе, алда әйтелгәнчә, халык алдында шифалы сулышлы табибка рәхмәт белдерә, уңышлар, игелекле хезмәтен дәвам итүне тели, яңа сеансларын көтеп алуларын белдерә.

Бу җәһәттән әйтү кирәк, теләүче райондашларыбыз аның сеансларына бара алалар. Доктор дәвалау сеансларын Казанда спорт сараенда 25—27 ноябрьдә һәм цирк бинасында 2—3 декабрьләрдә үткәрә. Мин, үзем сихәтен күргәнгә әйтәм: барсагыз, һич үкенмәссез, шифа алырсыз, савыгырсыз.

**М. МӨХӘММӘТГАЛИМ.**
Норлат шәһәре.

*Без үсәбез*
*нигып шулай,*
*үсәбез,*
*үсәбез,*
*үсәбез...*



Булган хәл

# „Миңа бирегез баланы...“

Хатыннарның бөтен
матурлыгы,
бөтен күрке ана булуда.
**Һ. ТАКТАШ.**

Хәлимә бер-ике көн инде авырсынып йөри. «Үтәр әле», дигән өмет белән иренә белдерәсе килмәде. Тик авыртуы көчәйгәч, күңелендә төрле шикләр туды: «Әллә әйтергәме, белдерсәм шифаханәгә озатыр инде», —дигән уйлар газаплады аны. Хәлимәнең һич тә анда барып ятасы килми иде. Үзе олыгаю ягына бара, китсә ире дә ялгыз кала: кем аңа ашарга пешерер, кем каршы алыр, озатыр? Шулай итеп ул сиздермәскә булган иде. Тик кичен чир үзенекен итте, ашыгыч ярдәм машинасы чакыртырга туры килде.

—Тиз генә эшкә барып хәбәр итим дә, мин дә килеп җитәрмен,—дип ире Хәлимәне озатып калды.

Хәлимәне чишендерү бүлмәсенә алып керделәр. Нәкъ шул чакта каршы ишектән чыккан хатын-кыз тавышы аны сискәндереп җибәрде, иртәнге каршылыклы уйлары кабат уянды:

Я хода, күңелем сизде микән, иртән үк килергә теләмәгән идем. Әллә кайтыйммы?

Тирә-як та шомлы тоелды аңа. Чишендерүче хатын да бик күңелсез иде.

Шул чак күршедән:

—Юк, алмыйм, миңа кирәкми,—дип аерымачык әйтелгән сүзләр яңгырады...—Әйе, баш тартам...

Тагын әллә нинди авазлар ялы җанга үтеп, тәнгә салкынлык йөгерттеләр. Чишендерүче апага бик авыр тәэсир итте булса кирәк, аның сулыш алуы кыенлашты, һәм, ниһаять, авызыннан бер сүз чыкты:

—И, ходаем, тагын бер ятим артты...

Хәлимә сискәнеп китте, бермәл тәне буйлап ниндидер җиңеллек йөгерде, бөтен нәрсә тукталгандай булды, аннан йөрәге еш-еш тибә башлады.

—Апа, апа, дим!—дип кычкырып җибәргәнен абайламый да калды.—Мин аны ятим итмим! Мин аны үземә алам, апа, дим, зинһар ярдәм ит!

Шифаханәдә киемнәр биреп торучы хатын әллә җавап бирде, әллә тыңлап кына торды, Хәлимә берни ишетерлек дәрәҗәдә түгел иде. Әйтерсең лә, барысын да хәл итүче шул хатын иде, ул аңа ялваруын белдерде.

—Апа, апакаем, бирегез миңа, безгә бирегез, без аны ятим итмәбез. Безнең балабыз юк, без аңа ата да, ана да булырбыз.

Хатын аны:

—Тукта әле, сеңелем, баланы болай гына бирмиләр бит, рәсмиләштерү эшләре бар, аннан иң элек иреңнең ризалыгы кирәк, —дип тынычландырырга кереште. Ә Хәлимә туктамады:

—Апакаем, зинһар врач белән сөйләшегез, ятим итмик...—дип үзенекен тәкрарлый иде.

Нәкъ шул чакта Хәлим дә килеп җитте. Хәлимә ашыга-тотлыга хәлне аңлата башлады.

—Бер яшь ана баласыннан баш тарта. Ир бала. Әнисез дә, әтисез дә, ятим кала. Алыйк үзебезгә, ятим итмик...

Хәлим, кинәт кенә шундый хәбәр ишетүеннән каушап калды, дулкынланды. Дымлы күзләрендә хатынына карата чиксез наз чагылды, гүя ул аны күккә чөяргә әзер иде.

—Хәлимә! Рөхсәт... Син дөрес эшлисең...

Тамагына капланган төер аңа сүзен әйтеп бетерергә ирек бирмәде.

Кием алыштыручы хатын:

—Ярый, сеңелем, сиңа киенергә кирәк, температураң югары,—дия башлаган иде, ләкин Хәлимә бу минутта икенче кеше иде инде. Шуны раслап, үзе дә көр тавыш белән:

—Апакаем, мин инде терелдем, яңадан тикшерсәләр дә, мин исән, әйе бит, Хәлим,—дип куйды.

Ул әле генә үзенең авыру икәнлеген бөтенләй онытты, үзендә әллә каршылыкларны җиңәрдәй көч, куәт хасил булуын тойды.

Алар бу мизгелдә бик бәхетле парлар иде. Ә нарасый, әтиле дә, әниле дә булды. Ул ятим калмады.

**Автордан: Билгеле сәбәпләр аркасында ата-ананың исемнәре алмаштырылды. Бу көннәрдә малайга бер яшь тулып килә. Ятимнәр исемлегендә булмавы белән аны бәхетлеләр исәбенә кертәбез.**

**И. ШӘЙХИЕВ.**
Зирекле авылы.




**Норлат шәһәрендә яшәүче әтиебез Мәҗидулла Әхмәдиевка 70 яшь тула. Без аны олы юбилее белән кайнар котлыйбыз, нык сәламәтлек, озын гомер, тыныч тормыш телибез.**

**Иң изге теләкләр белән УЛЛАРЫ, КЫЗЛАРЫ, КИЛЕННӘРЕ, ОНЫКЛАРЫ.**

**Норлат шәһәрендә яшәүче Кадрия Азат кызы Гыйльманованы туган көне белән котлыйбыз һәм изге теләкләребезне җиткерәбез.**

**Без телибез сиңа зур бәхетләр,**
**Күтәренке булсын күңелең,**
**Гөрләп яшә, картаюны белми,**
**Гел шатлыклы үтсен гомерең.**

**ӘТИСЕ, ӘНИСЕ, АБЫЙСЫ, ЭНЕСЕ.**

x x x

**Колбай Мораса авылында яшәүче хөрмәтле әтиебез Нәззәт Хәммәтрәхим улы Рәхимовны туган көне белән кайнар котлыйбыз. Аңа нык сәламәтлек, бәхет, матур тормыш, озын гомер телибез.**

**УЛЫ, КИЛЕНЕ, ОНЫКЛАРЫ.**

# ТЕЛЕВИДЕНИЕ

**ШИМБӘ**
**9 НОЯБРЬ**
**КАЗАН КҮРСӘТӘ**

17.20 «Ералаш». Киножурнал.
17.30 «Азат Мәргән». Ә. Фәйзинең повесть-легендасы буенча эшләнгән телевизион нәфис фильм. 2 нче серия.
18.10 «Яшьләр иҗаты». Шагыйрь Ф. Яхин.
18.40 «Бенефис». Г. Ильясов.
20.25 «Әлли-бәлли-бәү».
20.40 Тапшырулар программасы.

**I ПРОГРАММА**

6.30 Мультфильм.
7.00 Ритмик гимнастика.
7.30 «Эшлекле кешенең шимбә иртәсе».
8.30 «ТЯХ».
8.45 «Параллель дөньялар».
9.30 Иртәнге күңел ачу программасы.
10.00 «Бурда моден» тәкъдим итә...»
10.30 «Гонг».
11.30 «Сәламәтлек».
12.00 «Хайваннар дөньясында».
12.45 «Россия империясе коронасы яки «Яңадан тотылмаслар». Нәфис фильм. 1, 2 нче сериялар.
15.00 «ТЯХ».
16.45 «Экология яңалыклары».
17.00 «Халык музыкасына биюләр».
17.20 «Мәскәү шәһәре». 3 нче фильм.
17.50 Концерт.
18.05 Ашихара-каратэ буенча 1 халыкара Мәскәү турниры.
19.05 Мультфильм.
19.30 Кыска метражлы фильм.
20.00 «Бәхетле очрак».
21.00 Информацион программа.
21.40 «Ун негр баласы». Нәфис фильм. 1, 2 нче сериялар.
23.20 «ТЯХ».
00,05 «Кырым-91» автораллие.
00.35 «Биш плюс».

**II ПРОГРАММА**

8.00 Иртәнге гимнастика.
8.20 «Псков хәзинәсе».
9.00 «Кояшны көткәндә».
9.30 «Зооконференция». Балалар өчен фильм.
10.00 «Джаз-тайм».
11.00 «Плюс унбер». Видеоканал.
13.20 Музыкаль коллекция.
13.40 «Үлгәннән соң ант».
14.00 Теннис. «Кремль кубогы».
15.45 «Чистый Прудтагы йорт».
20.45 Кремльдә концерт.
22.00 Криминаль канал.
23.00 «Хәбәрләр».
23.20 Теннис. «Кремль кубогы».

**ЯКШӘМБЕ**
**10 НОЯБРЬ**
**КАЗАН КҮРСӘТӘ**

17.10 Мультфильм.
17.30 «Азат Мәргән». Ә. Фәйзинең повесть-легендасы буенча эшләнгән телевизион нәфис фильм. 3 нче серия.
18.10 «Идел киңлекләрендә». Киножурнал.
18.20 «Панорама». Информацион- публицистик программа.
20.00 «Әлли-бәлли-бәү».
20.10 Милиция хезмәткәрләре көненә багышланган концерт.

**I ПРОГРАММА**

8.00 Ритмлы гимнастика.
8.30 «ТЯХ».
8.45 «Спортлото» тиражы.
9.00 «Безнең бакча».
9.15 «Иртә таңнан».
10.00 «Ватанга хезмәттә».
10.30 «Иртәнге йолдыз».
11.30 «Уңышлар зигзагы».
12.30 «Сәяхәтчеләр клубы».
13.30 «Авыл сәгате».
14.15 «Кеше һәм закон».
15.00 «ТЯХ».
15.15 «Экологик бумеранг».
16.15 Биюләр «Супер-91 дөнья кубогы» (Германия).
17.20 «Авазлар күп — дөнья бер генә».
17.25 «Халыкара панорама».
18.10 «Уолт дисней» тәкъдим итә...»
19.00 «Ял кинозалы».
19.20 «Илле өченченең салкын җәе». Нәфис фильм.
21.00 Информацион программа.
21.40 Милиция көненә багышланган концерт. Тәнәфестә—«Футбол күзәтүе». «ТЯХ».

**II ПРОГРАММА**

8.00 «Зарядкага басыгыз!»
8.10 «Самарага монастырь нәрсәгә?». Видеофильм.
9.20 Документаль фильм.
10.00 Безнең яшьлек музыкасы.
10.45 «Дубль-В» Информацион-күңел ачу программасы.
11.15 «Билгесез Россия».
12.15 Халыкара театр фестивале.
13.10 Концерт.
13.40 «Изге һәм мәңге».
14.00 Теннис. «Кремль кубогы».
15.45 «СКВ».
16.00 Параллельләр.
16.30 Клоуннар фестивале. 2 нче тапшыру.
20.35 «Икенче рус революциясе». Документаль фильм. 1 нче серия.

**Норлат-Октябрь типографиясе коллективы әтисе үлү сәбәпле типографиянең кулдан хәреф җыючысы Д. К. Вәлиәхмәтованың тирән кайгысын уртаклаша.**

**МӨХӘРРИР Ә. У. АБДУЛЛИН.**

**Учредитель: халык депутатларының Октябрь район Советы.**
**Газетада язмалары басылган авторларның фикерләре бу әле редакция фикере дигән сүз түгел.**

**РЕДАКЦИЯНЕҢ АДРЕСЫ: 423000, Норлат шәһәре, К. Маркс урамы, 19.**
**ТЕЛЕФОННАР: мөхәррир—2—12—14, 2—22—81, мөхәррир урынбасары—2—10—44, рус теленә һәм чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир урынбасарлары —2—15—63, социаль-экономика бүлеге— 2—22—51, җаваплы секретарь—2—14—16, хатлар бүлеге һәм бухгалтерия—2—18—67.**

**Газетаны Фидания ХӘЙРЕТДИНОВА җыйды. Римма ГАНИЕВА верстка ясады. Клара БОБКОВА басты. Корректор Зөлфия ВӘЛИЕВА.**

**«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**
**ТССР информация һәм матбугат Министрлыгының Норлат-Октябрь типографиясе.**
**Күләме—1 басма табак.** Заказ 133. Тираж 3413.